**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Сарабиккол авыл җирлегенең**
**Сарабиккол торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабикколавыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабикколторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Такташ урамындагы иске агачларны кисү; Такташ урамына балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру; үсентеләр (чәчәкләр) алу; Сарабиккол авылы территориясендә кул белән үлән чабу; МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу); тракторчы хезмәтенә килешү буенча түләү (территориядә коры һәм чүп үләне чабу, полосаларны минеральләштерү һәм сукалау, башка эш төрләре));

2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү ("тегермән чишмәсе " чишмәсен капиталь ремонтлау һәм аңа якын территорияләрне төзекләндерү);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кар чистарту өчен җиһазлар сатып алу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол

авылы, Пионер урамы, 45 йорт - "Сатурн-Урал" ҖЧҖ, Киров ур., 3А йорт - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Киров ур., 4А йорт - мәдәният йорты бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина